Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Олы Елга авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

13 ноябрь 2025 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Олы Елга авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре), 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, халыкка су бирүне (җибәрүне) тәэмин итүче суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын, су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмалары урнаштыру;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- традицион мәет җирләү урыннарын (зиратларны) ремонтлау, төзекләндерү, киртәләп алу.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы. Ф.Ш.Сәйфетдинов